ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 июнь 2016ел № 3277

«Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Инвалидлар хокуклары турында Конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 10 июнендәге 3480 номерлы карары (Башкарма комитетның 2014 елның 31 гыйнварындагы 533 номерлы карары редакциясендә) белән расланган «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3.3. пунктының 1 пунктчасын «Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) муниципаль хезмәт турында булган мәгълүматларны үз эченә ала» сүзләре белән тулыландырырга»;

2) 1.5 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата.)»;

3) 2.4 пунктның беренче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату, әгәр мөмкинлек Россия Федерациясе законнарында каралган булса»;

4) 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1) Хезмәт күрсәтү турында гариза;<br>2) Шәхесне таныклаучы документлар;<br>3) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);<br>4) Гариза бирү датасына кадәр ике ел дәвамында, яисә товар төрләре, җитештерелгән һәм (яки) сатылган товарларның исеме, товарларның төрләрен күрсәтеп, ике елдан да ким булмаган эшчәнлек алып бару срогы дәвамында, әгәр ул товар төрләрен күрсәтеп, ике елдан да ким булмаган күләмдә булса, эшчәнлекне гамәлгә ашыру срогы дәвамында;<br>5) Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре турында расланган мәгълүматлар.<br>Гаризалар һәм документлар бер нөсхәдә тапшырыла.<br>Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьләрдә түбәндәге ысулларның берсе белән бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:<br>- шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч язуы нигезендә эш итүче зат);<br>- почта аша заказлы итеп, җибәрү турында белдерү кәгазе белән. |

| | |
|---|---|
| | Гариза һәм документлар, шулай ук, гариза бирүче тарафыннан, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша һәм Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырылырга мөмкин.» |

5) 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе;<br>документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы һәм оешмалар | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>1) ЕГРЮЛдан мәгълүматлар яисә ЕГРИПтан мәгълүматлар;<br>2) Законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүматлар;<br>3) бухгалтерлык балансыннан мәгълүматлар (шул исәптән керемнәр һәм чыгымнар турында хисап).<br>Гариза бирүченең документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән;<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмау гариза бирүченең хезмәт күрсәтүдән баш тартуы өчен нигез булып тормый»; |

6) 2.7 пунктында:

- беренче баганаы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче дәүләт хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт

органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге»;

- икенче багананың 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«(2) яшәешне тәэмин итүнең тиешле өлкәсенә кураторлык итүче Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары яисә тармак органы башлыгы (алга таба – тармак органы Җитәкчесе);»;

7) 2.13 пунктының беренче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада гариза бирүченең запросын теркәү срогы»;

8) 2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр» | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм биналарда башкарыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (бинага керү-чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү уңайлы).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. |

9) 2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итүләре саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтүне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) бинаның җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>2) кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>3) мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http://www.nabchelny.ru), Татарстан |

| | |
|---|---|
| үзәкнең читтәге эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацон технологияләрне файдаланып | Республикасы Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru) муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>4) инвалидларга башка затлар белән бертигез хезмәт күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны узарга ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>1) документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә документлар биргәндә чиратлар;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>3) муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;<br>4) муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтәге эш урыннарында күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ хезмәткәре гамәлгә ашыра.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче шәһәр сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, КФҮдә ала ала. |

10) 3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3. «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре»;

11) 3.3.3 пунктның беренче, өченче абзацларындагы «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына» сүзләрен «Җитәкчегә» сүзенә алмаштырырга;

12) 3.3.4 пунктында «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «Җитәкче» сүзенә алмаштырырга;

13) 3.5.3. пунктында тиешле килештәге «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен тиешле килештәге «Җитәкче» сүзенә алмаштырырга;

14) 3.8. пунктны түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) техник хатаны төзәтү турында гариза (5 нче кушымта);

2) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

3) техник хаталар булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша бирелә.

3.8.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең документларны кабул итү өчен җаваплы белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны һәм теркәлгән документларны кабул итүне, теркәүне гамәлгә ашыра һәм аларны Башкарма комитет Җитәкчесенә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза һәм документларны карап тикшерә һәм тармак органы Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен тармак органы Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.8.4. Тармак органы Җитәкчесе документларны карап тикшерә һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында әлеге Регламентның 3.3.3, 3.3.4, 3.5 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, һәм техник хата булган, төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) төп нөсхәсен, имза куйдыртып, шәхсән үзе бирә яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта аша) техник хата булган документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хатаны ачыклаганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.»;

15) 3 нче кушымтада тиешле санда һәм килештәге «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен тиешле санда һәм килештәге «җитәкче» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә. А. Галиәкбәровага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — В.А. Гаврилов

Башкарма комитетның
2016 елның 27 июнендәге
3277 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесенә
___________________________
Кемнән_________________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
___________________________________________________________________________
(хезмәтнең исеме)

Язылган: ____________________________________________________________
___________________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: _______________________________________________________
___________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: ______________________ адресына җибәрү юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне:
__________________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү

максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

_______________ ___________________ ( __________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева